ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**27.03.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 822**

Зеленодольск муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру схемасы килештерелергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеген раслау турында

2017 елның 29 декабрендәге«Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 443-ФЗ номерлы Федераль законның 9 өлешенең 18 статьясы, 2018 елның 20 декабрендәге«Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру схемасы белән килештерелергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеген әлеге карарның кушымтасында каралганча расларга.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 27 мартындагы
822 номерлы карарына
кушымта

**Зеленодольск муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру схемасы белән килештерелергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеге**

1. Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлегенең Дәүләт автоинспекциясе бүлеге (килешү буенча).
2. Автомобиль юллары хуҗасы яки оператив идарәсендә Зеленодольск муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юллары булган һәм аларга юл хәрәкәтен оештыру схемасы эшләнә торган орган.